
**Роберт МИҢНУЛЛИН,**

Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.



# ҖИР БЕЛӘН КҮК КЕШЕСЕ




"Сак белән Сок". 96


Сәеррәк кеше ул Хәмит. Мин аны утыз елдан артык беләм инде. Әмма һаман аңлап бетерә алганым юк. Киресенчә, очрашкан, күрешкән саен яңа яклары белән ачыла. Бер килгәндә керамикадан ясалган ниндидер мифик сыннар төяп килә. Икенче килүендә пастель белән язылган зур-зур картиналардан күргәзмә ачып китә. Өченче килүендә спонсорлар ярдәмендә басылып чыккан шигырьләр китабын чыгарып сала. Һәм шунысы кызык, нигә генә тотынмасын, ни белән генә шөгыльләнмәсен, таланты, кабатланмас үз йөзе ярылып ята... Бу юлы да Туймазыга нинди хыяллар белән кайтып киткәндер? Чираттагы килүендә тагынниләр белән шаккатырыр? Шайтан белсен... Мин аның беренче эшен моннан күп еллар элек мәрхүм шагыйрь Ринат Хәйридә күргән идем. "Шүрәле" исемле рәсем иде ул. Әле дә күз алдымда: без белгән шүрәлегә охшаган да, охшамаган да иде ул. Ләкин, ни хикмәт, Хәмитнең шүрәлеләр белән шаяруы кәсепкә әйләнгән булып чыкты. Ул һаман да шул шүрәлеләр, җен-пәриләр, шайтаннар, убырлар, Сак-Соклар белән җенләнә. Ул җан ияләре безгә шулкадәр таныш, әйтерсең лә, балачакта бергә уйнап үскәнбез. Хәер, шулай да бит инде.

Аның картиналары да ничектер күңелгә үтә дә якын. Аларда төркилек тә, мөселманлык та, шәрекълек тә ярылып ята. Әмма иң элек барыбер татарча алар. Чын татарча. Әкияти татар дөньясы. Борынгылыгыбызны да күрәм мин аларда. Әллә бүгенгебез микән? Юктыр, рухи дөньябызны алай бүлеп карарга ярамыйдыр. Фәкать үзебезнең татар дөньясы бу. Хәмит Латыйпов тудырган серле дә, шул ук вакытта реаль дә дөнья...

Хәмит җен-пәриләрнең, шүрәлеләрнең телен беләдер, алар белән сөйләшәдер, әңгәмә корадыр кебек миңа. Андый кеше Ходай белән сөйләшергә дә күп сорамас...



"Таулар моңы"



"Көтүче"